**СОВЕТ СЕЛО-АЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422721, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Алат, ул. Первомайская, 32

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422721, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алат авылы, Беренче май урамы, 32

тел./факс 8(84365) 63-2-25, e-mail: Salat.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**10 ноябрь 2023 ел.** **№ 77**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында»2015 елның 15 октябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Село-Алат авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 9 номерлы карарына (советның 24.04.2018 ел, № 97, 23,08.2018 ел, № 108, 27.12.2018 ел, № 129, 28.11.2022 ел, № 61 карары редакциясендә), 05.09.2023 no 73) түбәндәге үзгәрешләр:

3 нче пунктның 3.2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

"3.2 Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге территориясендә мөлкәткә ия булган Россия Федерациясе физик затларын мөлкәткә салым түләүдән азат итәргә.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык урынбасары
Алат авыл җирлеге авылы
Биектау муниципаль районы И. К. Хөснетдинов